| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«18» сентябрь, 2025 ел Олы Кайбыч ав. № 5

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итүне 2025 елның 26 сентябреннән 16 октябренә кадәрТатарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы Бульвар урамы, 3 нче йорт, 7 нче бүлмә (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе бинасы) адресы буенча шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул итәргә, тел.2-11-02.

2. Конкурс комиссиясенә Конкурсны 2025 елның 17 октябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы Бульвар, урамы 3 нче йорт, 7нче бүлмә (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе бинасы) адресы буенча үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советына тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составын 6 кеше санында расларга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясенең 3 кешедән торган ярты составын кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны «Кайбыч таңнары» газетасында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы — А.И. Рәхмәтуллин

Совет Большекайбицкого сельского поселения
Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000502

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының
2025 елның 18 сентябрендәге
5 номерлы карарынакушымта

# КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КАНДИДАТУРАЛАР КАРАУ ӨЧЕН КОНКУРС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫНЫҢ ЯРТЫСЫ

1. Хәмидуллин Ильяс Илдар улы, 6 номерлы Сирень бермандатлы сайлау округы депутаты;
2. Фенагентова Наталья Владимировна, 8 номерлы Симәки бермандатлы сайлау округы депутаты;
3. Габидуллин Илшат Сәлимҗан улы, 9 номерлы Мәктәп бермандатлы сайлау округы депутаты.